СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.09.2017 с. Нижний Услон 35-136

Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы буенча ташламалар бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ, «Ирекле янгын саклау турында» 06.05.2011 ел, № 100-ФЗ, «Татарстан Республикасында ирекле янгын саклау турында» 01.08.2011 ел, № 48-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законнарга Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Җир салымын түләү буенча түбәндәге категория салым түләүчеләргә җир салымының кадастр бәясеннән 0,2% күләмендә киметелгән ставкасын куллану рәвешендә салым ташламасын күздә тотарга:

- ирекле янгын сүндерү берләшмәләренә;
- ирекле янгын сүндерүче хезмәткәрләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә.

2.Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 абзацында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата бирелә, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган ташламалар салым түләүченең теләге буенча бары тик бер җир участогы өчен генә бирелә.

3.Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир салымы ташламалары хокукына ия затлар салым салу объекты дип танылган мөлкәтнең урнашу урыны буенча салым органына әлеге ташламаны алу хокукын раслаучы документларны мөстәкыйль рәвештә тапшыралар.

4.Әлеге карар үз гамәлен 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А. З. Шәйдуллин